Резеда **Валеева**

**ПЕСНЬ О ДЖАЛИЛЕ**

Поэма

Казань
Татарское книжное издательство
2011

Резеда **Вәлиева**

**МУСА ҖӘЛИЛ – ХАЛКЫМ УЛЫ**

Поэма

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2011

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
В97

Русчага *Сергей Малышев* тәрҗемәсе

Перевод на русский *Сергея Малышева*

Рәссамы *Рөстәм Хәбибуллин*
Художник *Рустем Хабибуллин*

**Вәлиева, Р.Т.**

Муса Җәлил – халкым улы : поэма = Песнь о Джалиле : поэма / Резеда Вәлиева. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 63 б.
ISBN 978-5-298-02025-1

Шагыйрә Резеда Вәлиеваның әлеге поэмасында Советлар Союзы Герое, каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тиңсез батырлыгы тәэсирле сәнгать образлары ярдәмендә тасвирлана.

Поэма поэтессы Резеды Валеевой ярко, образно, красочно раскрывает суть подвига Героя Советского Союза, поэта-героя Мусы Джалиля.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02025-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Вәлиева Р.Т., 2011

*Исеме аның яңгырый җыр булып*

Татар әдәбияты күренекле шәхесләрнең якты исемнәренә бик бай. Алар арасында каһарман шагыйрь Муса Җәлил исеме аеруча якты йолдыз булып балкый.

СССР Югары Советы Президиумының 1956 елгы 2 февраль Указы белән Бөек Ватан сугышында немец-фашист илбасарларына каршы көрәштә күрсәткән тиңсез чыдамлыгы һәм батырлыгы өчен Муса Җәлилгә үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Ә тагын бер елдан соң СССР Министрлар Советы каршындагы әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин һәм Дәүләт премияләре Комитеты шагыйрьләр арасыннан беренче булып Муса Җәлилгә «Моабит дәфтәре» шигырьләр циклы өчен Ленин премиясе бирү турында карар чыгарды.

Бүгенге көндә Муса Җәлил бер үк вакытта шушы ике югары дәүләт бүләгенә лаек булган бердәнбер язучы булып кала. Бу инде иксез-чиксез илебез халыкларының Җәлил шигъриятен каһарманлык сәнгатенең иң югары үрнәге итеп тануын, бәяләвен күрсәтә.

Җәлилнең бер җыентыгына кереш сүзендә Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим болай дип язган иде: «Муса Җәлил кебек уллары булган татар милләтенә без бик тә рәхмәтле. Нәкъ менә Җәлил кебекләр, илнең тулы хокуклы вәкиле сыйфатында, Ватаныбызны бөтен дөнья халыклары һәм кавемнәре багланышында гәүдәләндереп күрсәтәләр. Кешеләр татар халкының акылы һәм күңеле, йөрәге турында аның менә шушындый улларына карап фикер йөртәләр».

Бүген дә, ничә дистә еллар узганнан соң да, Җәлилнең батырлыгы гражданлык идеалларына тугрылык һәм кыюлык билгесе булып хезмәт итә, ә аның иҗади мирасы бөтен халыклар өчен уртак хәзинә булып тора.

Резеда Вәлиева үзенең поэмасында татар шагыйренең батырлыгын, аның асылын җиңел аңлаешлы телдә якты, тәэсирле сәнгать образлары ярдәмендә тасвирлый. Шушы әсәр аша шагыйрьнең уй-хисләрен, күргән газапларын үз күңеленнән, үз йөрәгеннән кичергән яшүсмер беркайчан да начарлык кылмас, Ватанының тугры улы булып үсәр дип ышанам.

Бөек Ватан сугышы вакыйгалары бездән ерагайганнан-ерагая бара. Узган сугышны китаплар һәм фильмнар аша гына белгән яңа буыннар үсеп җитте. Ә халкыбыз каһарманлыгы онытылмый. Муса Җәлил дә мәңгегә безнең белән. Бүгенге көндә урамнар, колхозлар, театрлар, пароходлар аның исемен йөртә. Татарстанның нефть төбәгендәге бистә, Яр Чаллы шәһәренең үзәк проспекты, БАМдагы яшь Беркакит бистәсенең урамы, Антарктиданың иң биек түбәсе һәм Кырымдагы астрофизик обсерваториядә ачылган кече планета – астероид аның исеме белән аталган.

Казанда, Кремль каршындагы Беренче Май мәйданында, Муса Җәлил батырлыгын чагылдырган һәйкәл куелган (авторы – скульптор В.Е.Цигаль). Әмма каһарман шагыйрьгә һәм узган сугышта башларын салган ил батырларына иң зур һәйкәл – ул Җәлил шигырьләре.

Төрмәләрдә сакланып калып туган илебезгә кайткан шушы кечкенә генә дәфтәрләрдән дистәләгән телләрдә китаплар дөнья күрде. Илебездә генә түгел, дөньяның төрле кыйтгаларында миллионлаган данәләрдә таралдылар алар. Тыныч тормышка, хезмәткә гашыйк кешеләр, якты киләчәккә өмет белән караучылар шагыйрь иҗатын яратып кабул иттеләр.

Мин сезгә бу китапны күңел биреп, игътибар белән укырга киңәш итәм. Ышанып әйтәм: бу әсәр сезнең күңелләрегездә Җәлилнең үз шигырьләрен кулыгызга алып укыйсы, аның турында күбрәк беләсе килү теләге уятачак. Каһарман шагыйрьнең җыр булып яңгырап үткән гомере сезнең өчен тиңдәшсез үрнәк бит ул.

*Рафаэль Мостафин*,

язучы, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт һәм Муса Җәлил исемендәге Республика премияләре лауреаты

*Муса Җәлил – халкым улы*

*Гомерем минем моңлы бер җыр иде,*
*Үлемем дә яңгырар җыр булып...*

*Муса Җәлил*

*– Муса Җәлил!..*
*Нинди матур исем...*
*Моңлы да күк үзе,*
*горур да.*
*Моңлы җырдай гүзәл гомер юлы...*
*Гаҗәп бит бу...*
*Аның турында*
*Беләсе иде тагын,*
*тагын да.*
*Сөйлә миңа, әнием!..*

*– Тыңла, улым,*
*Һәм онытма моны гомереңә,*
*Шагыйрь үткән олы көрәш юлы*
*Якты мирас булсын күңелеңә.*

*Муса Җәлил – бөек халкым улы,*
*Гасырларга калсын гомер юлы.*

СУГЫШ

...Таң беленә,
офык алсулана.
Тып-тын өйләр,
кырлар,
үзәннәр.
Көмеш чыклар кунган миләүшәләр
Күк башларын түбән игәннәр.
Агачларга алсу нур йөгергән,
Сүрелеп килә төннең карасы.
Сыңар күзен кысып,
тәмләп кенә,
Сузылып куя куян баласы...
Ә бишектә
нәни генә бәби,
Алсу иреннәрен бөтереп,
Чупылдатып-чупылдатып куя, –
Йоклый әле тәмле төш күреп...

Менә шунда кинәт,
күк күкрәтеп,

Бомба ява башлый өйләргә.
Ут һәм ялкын ява,
үлем ява
Җылы яңгыр көткән җирләргә...
Әлеге тын өйләр,
куянчыклар,
Бишектәге нәни бәбиләр,
Ут эчендә кала
уенчыклар,
Ут эчендә кала
әниләр...
Илебезгә шулай килде фашист –
Кешелекнең явыз дошманы
Һәм дошманы дуслык,
тынычлыкның –
«Палач» диеп атый
Җир аны!
Күтәрелде Ватан зур көрәшкә,
Күтәрелде яуга кешеләр:
очучылар,
иген игүчеләр,
йортлар төзүчеләр,
эшчеләр.
Күтәрелде иңне иңгә куеп,
Күкрәк белән каплап Ватанын,
Саклап калыр өчен
Туган җирен,
Тын кичләрен аның,
ал таңын.
Ватан-ана!..
Шушы сүзгә сыйды
яшәү көче,
Шушы сүздә – бөтен теләкләр.
«Ватан!» диеп кеше
утка керде,
«Ватан!» диеп типте йөрәкләр.
Менә шулай халык,
ташкын булып,
Ватан өчен утка атылды.
Менә шуңа күрә
бу зур сугыш
Ватан сугышы дип аталды.

## БАЛАЧАК

Россиядә,
иркен, киң далада,
Уйчан гына тын бер авылда
Туды шагыйрь,
кыю лачын кебек,
Кичәр өчен
утлар,
давыллар...
Кечкенәдән ялантәпи аның
Далаларын айкап үскәнгә,
Челтер чишмәләрнең
көмеш суын
Учларына алып эчкәнгә,
Мәхәббәте газиз Туган җиргә
Үзе белән бергә үсте аның.
Чыңлап очкан
тургай тавышлары
Күңел моңнарына күчте аның...

Еллар үтте.
Шанлы еллар аны
Иле сөйгән шагыйрь иттеләр.
Еллар үтте.
Авыр еллар аны
Сынауларга алып киттеләр...
Афәт килде илгә.
Сугыш килде...

## ШАГЫЙРЬ ФРОНТТА

Ул фронтта.
Әрни шагыйрь:
Туган илем минем,
Танымаслык булып үзгәрдең,
Кансыраган яраларың күреп
Өзгәләнә минем үзәгем...
Ак йортларың кара күмер булган,
Шәһәрләрең янган,
таланган.
Гөрләп торган гүзәл гөлбакчадан
Мыскылланган кара җир калган...

Япь-яшь ана ята
кан эчендә,
Күкрәгенә кыскан баласын...
Беренче кат күрәм
бу дөньяның
Вәхшиләрен мондый,
палачын!
Көрәш авыр.
Фашист ерткычлана,
Кан исеннән гүя исерә.
Көрәш авыр,
көчләр тигез түгел,
Волхов кыен көннәр кичерә.
Һәм соңгы көн менә...

Кая баксаң,
шунда ут һәм ялкын,
Җир белән күк
гүя тоташкан.
Ничә көннәр,
ничә төннәр инде
Ут эчендә шагыйрь
тоташтан...
Ут эчендә...
Җаны көйри аның,
Күкрәгеннән ялкын бөркелә.
– Газиз Туган җирем,
исән булсам,
Бирмәм сине
фашист этенә!
Бирмәм...
Этләр, ягез,
йә килегез!..
Чү, ни булды?
Шагыйрь егыла.
Ә фашистлар килә,
алар бик күп...
– Пистолетым!..
Тешен кысып шагыйрь сузыла...
– Пистолетым!..
Соңгы сүзем сиңа:
Каным тамган җиргә егылып,
Туфрак булып калыйм...

Пистолетым!..
Юк, тыңламый...

Кайнар башы белән
кан эченә
Авып төшә шагыйрь,
сыгылып...
Күзен ачса,
кара өер кебек,
Дошман аның тирә-ягында,
Була микән җирдә хурлыкларның
Авыррагы моннан тагын да?!

* * *

Алар шулай
изге,
шат күңелле
Хөр шагыйрьне
әсир иттеләр.
Кулларына богау салдылар да
Кол итәргә алып киттеләр...
– Кичер, илем,
соңгы тамчы каным
Синең туфрагыңа таммады.
Гомер юлым синдә чиклим диеп
теләсәм дә,
Үлем алмады...

Тик куанма, фашист,
тырнагыма
Эләктердем диеп Бөркетне.
Яралы да канат,
антым – изге,
Каным белән аны беркеттем!
КОНЦЛАГЕРЬДА

Әсирләрне,
кара тамга сугып,
Китерәләр Герман җиренә.
Концлагерь...
Монда, кан-дәһшәттән
Куркып,

үлем үзе чигенә...

Яралардан савыгып килә шагыйрь,
Тик йөрәге әрни,
гел әрни.
Туган иле,
үзе,
ирege өчен
Көрәш даулый йөрәк,
гел даулый.

Концлагерь...
Монда җаннар көйри,
Монда – вәхшәт,
монда – күз яше.
Монда – ачлык,
монда – мыскыллаулар,
Ә син – Кеше,
шуңа түз,
яшә!
Юк, ул түзмәс!

## КӨРӘШ

Ул көрәшкә чыга...
Әкрен-әкрен
Якыннарын таба,
ишләрен.
Күзләр белән генә хәбәрләшеп
Аңлашалар йөрәк хисләрен.
Көрәш, дуслар!
Яшәү бүген – көрәш!
Нык торыгыз,
бердәм булыгыз.
Бары көрәш,
авыр көрәш аша
Туган илгә безнең юлыбыз!..
Фашизмның сына сырт сөяге,
Бөек Рейхның ава әләме.
Рейхминистр
Альфред Розенберг
«Милли легионнар» әвәли.
Ябык лагерьларда,

тоткын коштай,
Шагыйрь тилмерүен белгәннәр.
Юха елан булып,
бөтерелеп,
Аны эзләп
шунда килгәннәр.
Әйтә Розенберг:
– Синнән – хезмәт.
Бездән сиңа
хөрмәт,
мал,
ирек!
Гомер бит ул
тик бер генә килә...
Рәхәтләрен аның
кал күреп...
Сузма, шагыйрь:
безнең вакыт бик тар.
Ризалыгың бир дә,
килешик.
Шәфи Алмас* тора:
– Әйе, әйе,
Изге эшкә бергә керешик!
– Без телибез
татар-башкортлардан
Милли легионнар төзергә.
Озатырга аны
Көнчыгышка –
Фронт сызыгына –
тиз генә.
– Ә сез безгә шушы адәмнәрне
Үгетләргә ярдәм итәрсез...
Газета аша...
Бәясе бит – ирек!
Ник дәшмисез?
Нәрсә көтәсез?
Үзегезгә,
яшәү тәкъдим итеп,
Рейх күрсәтә шундый игелек!
Юкса!..
– Куркытмагыз,
шагыйрь өчен җирдә
Туган илдән башка

юк ирек!

Юмалыйлар
Рейх бүреләре,
Хәйлә белән сүзне боралар:
– Сез бит шагыйрь,
ә шагыйрьләр алар
Сыйныфлардан өстен торалар...
Безгә ярдәм кирәк!..

– Ярдәм, димсез?..
Муса уйга кала.
Балкып китә коңгырт күзләре:
«Тукта, тукта...
Ул бит үзе
көрәш өчен
Бу юлларны күпме эзләде...
«Ярдәм», «ярдәм»...
Әйе, әфәнделәр,
Начар булмас
«ярдәм итә» алсак,
Шушы «ярдәм» белән лагерьларга,
Легионнарга үтеп керә алсак.
Фашистларның борын төпләрендә
Үлем ятьмәләре үрә алсак?!»
Көрәш...
Ул дәрт бирә
шагыйрь йөрәгенә,
Өмет уты кабыза күңелгә.
«Туган илкәй,
кавышулар килер,
Аерылышу булмас гомергә».

Давылларда туган лачын кебек,
Ул көрәштә үсә,
чыныга.
Яши башлый янә
солдат булып,
Үч кылычын суырып кыныннан...

Тик хәзергә әле ул берүзе,
Ә кирәк аңа ун,
йөз,

мең кылыч.
Лагерьларда йөри...
дуслар эзли,
Юлы хәтәр,
юлы куркыныч...
«Көрәштәшләр табып,
дошманыңны
Җиңеп чыгар өчен
кер утка!»
Һәрнәрсәгә күзең җитсен монда –
Кылны яра шагыйрь кырыкка...
Сандугачлар булып
өмет кошы
Куна аның күңел талына:
Листовкалар басу,
очрашулар,
Элемтәләр юлга салына.
Үзе белән дусты Алиш аның,
Якташлары,
көрәштәшләре,
Серле йомгак кебек,
әкрен генә
Үсә бара изге эшләре...
Хыялларда инде –
зәңгәр офык,
Таралалар канлы томаннар...
– Давылларны кичкән
бөркетләрдәй,
Без кайтырбыз Илгә, туганнар!
Кайтмый калсак
көрәш кырларында,
Башны салсак
Җиңү хакына,
Иле өчен үлгән улларының
Исемнәре кайтыр халкына...

Шулай яши шагыйрь
рухландырып
Илдәшләрен тирә-ягында.
Ялкыннарда җаны корычланды,
Ул бөгелмәс кыен чагында!
ЛЕГИОНЕРЛАР БЕЛӘН ХУШЛАШУ

Күп көч куеп,

фашист ялчылары
Легионның милли частьларын
Озаталар бүген
фронтка дип,
Күбесе татар-башкорт яшьләре.
Озаталар...
Йөзләр кырыс:
өсләрдә ят шинель –
Җанны кыса мондый шинельләр.
Күптән аны умырып атар иде
Нәфрәт белән тулы күңелләр!
Тик түзәргә кирәк!..
Бирешмәскә,
Сынатмаска соңгы минутта.
Максат-антың истә:
«Дошманыңны
Җиңеп чыгар өчен
кер утка!»
Муса дулкынланган,
соңгы тапкыр
Күзләр белән күзләр очраша.
Әйтерсең лә шагыйрь
һәр илдәшен
Күкрәгенә кысып хушлаша.
– Очыгыз, оч,
лачыннарым минем,
Туган илгә тизрәк җитегез,
Улларыннан сәлам илтегез,
Һәм безне дә тиздән көтегез.
Без кайтырбыз...
Алман җирләреннән
Үлем алалмаслык юл үтеп.
Җиргә афәт салган
диюләрнең
Үз өнендә үзен көл итеп!

Сез әйтегез Илгә сәламнәрне,
Сагынуларны безнең әйтегез.
Хисләремнең тугрылыгы итеп,
Җырларымны аңа илтегез...

## КУАНЫЧ

Хәбәр килә тиздән,

шатлык килә, –
Морадына шагыйрь ирешкән:
Бик күп частьлар яңа батальоннан
Кушылганнар барып көрәшкә!
Кушылганнар!
Тик дошманга түгел,
Көрәшәләр Совет ягында!
Ничек түзсен йөрәк
үч алмыйча,
Кулда корал булган чагында!
Корал! Корал!!
Куллар йодрыклана.
Тукта, йөрәк, шашып типмә син.
Сизенмәсен дошман уйларыңны,
Өметләрне кылыч кисмәсен...
Сәгать сугар,
тиздән без дә менә,
Бөтен лагерь белән тупланып,
Кузгалырбыз
язгы ташкын кебек,
Дошманнардан канлы үч алып!

Янып яши шулай җәлилчеләр,
Куанычлар сыймый эчләргә.
Ә фашистлар сатлык этләр яллый,
Оешманың эзенә төшәргә...
ХЫЯНӘТ

Кайчак алтын бодай басуында
Чүп үләннәр очрап куйгалый,
Нурга тулып пешкән алмаларның
Үзәкләрен кортлар ергалый.
Ә кайчакта хәтта
кешеләр дә,
Кешеләр дә була үзәксез.
Тыштан кеше төсле,
ә чынында
Җансыз алар,
илсез-йөрәксез!
Җыерылып сасы көзән кебек,
Калтырый ул дошман алдында,
Нурдан курыккан сукыр тычкан кебек,
Куркып яши
Кеше янында.

Төн килсә дә курка,
таң атса да,
Көн яктысы балкып торса да.
Куркып яши
сатлык җаны өчен,
Үзе күптән үле булса да...
Шушы мескен гомере хакына ул
Барысын да әзер сатарга:
Килеп керә хаин,
битлек киеп,
Соңгы сәгать сугар чакларда...

Соңгы сәгать!..
Нигә сукмый калды?!
Богау чыңы белән таң атты?.. –
Кара елан булып чакты хаин,
Агуларын ерак таратты...

## ТӘМУГ ГАЗАПЛАРЫНДА

Ирек...
Якын идең,
ярсу йөрәкләргә
Өмет чаткылары салдың да,
Уйнап очкан ак күгәрчен кебек,
Югалдың син...
Янә алдымда
Таш стена.

Куллар богауланган.
Аяклар шеш.
Тәннәр таланган.
Аһ!
Кем икән ул?
Кем ул –
хыянәтче?!
Күңел кайда,
кемдә алданган?!
Өзгәләнә шагыйрь,
таш камера
Караңгы гүр белән тиң аңа.

Йөзе кара янган,
ярасыннан
Таш идәнгә кайнар кан тама...
Ә иптәшләр, Алиш,
Курмаш кайда?
Их! Әйтәсе иде лә күреп:
«Үзе өчен туа,
халкы өчен яши,
Иле өчен үлә ир-егет!»
Шундый уйлар миен телә аның,
Күз алдына килә дуслары,
Өметләре,
шашкын хыяллары,
Уйларының ләкин очлары
Очларына барып ялганалмый,
Ул саташа башлый,
аңында
Иптәшләре һаман...
Алар, имеш,
Барысы бергә,
аның янында.
Әнә Алиш,
ап-ак йөзе буйлап
Кан агамы шулай,
яшьме ул?
Эндәшсә дә Муса,
ул эндәшми.
Ник сөйләшми,
нигә дәшми ул?!
Сүзсез генә шулай моңсу карап
Үзәкләрне нигә өзә икән?
Күзен ачса,
тәне ут эчендә...
Аһ!
Адәм җаны түзсә түзә икән...
Ниләр күрсәтмәде палач аңа,
Ничек кенә үчен алмады,
Нинди сынауларда сынамады,
Нинди ялкыннарга салмады!

Сөлек булып
канын эчте аның,
Бүре булып

жанын кимерде.
Шагыйрь түземенә түзалмыйча,
Ахыр үзе шашып илерде:
– Кемнәр тагын синең иярченнәр?!
Кемнәр алар?!
Йә, әйт?!
Бер сүзең
яшәү бирер сиңа,
ирек бирер!..
Тик җавап бер һаман:
– Берүзем!

Котырынып тагын ташланалар,
Аяк-кулын борып тарталар.
Кыйнап арыгач,
капчык кебек сөйрәп,
Таш идәнгә кертеп аталар...
Күпме түзде шагыйрь бу газапка,
Атналармы,
аймы,
еллармы?
Ничә үлеп,
ничә терелде ул,
Кем исәпләр бүген аларны?!
Моабитның авыр ишекләре
Газапларын аның чәчмәде.
Тик шунысын яшералмады алар:
«Түзде шагыйрь.
Түзде.
Дәшмәде...»

## СУД

Суд алдында шагыйрь
басып тора.
Нәфрәт уты ургый күкрәктә.
Күз карашы хәтта
палачларның –
Ерткычларның җанын тетрәтә.
Йодрыклары каты төенләнгән,
Күкрәк киерелгән,
йөз кырыс.
Куырылып килә гитлерчылар:

«Аһ, бу татар
нинди куркыныч!»
Ачу белән янган күзләрендә
Сихерле көч,
афәт бар сыман,
Җиңалмаган аны газаплар да,
Сынмаган ул, –
тагы да ярсыган!
Сөйли шагыйрь
ярсып,
янып сөйли
(Кайчан сөйләр шулай ул тагын):
– Гаеп итеп
җирдә кешеләрнең
Яратуын газиз Ватанын,
Сез җинаять уйлап чыгардыгыз,
Сез хыянәт миңа тактыгыз,
Яшерер өчен мине Ватанымнан
Төпсез упкыннарга аттыгыз!
Ләкин!
Мин бәхетле,
якты уйларымның
Үти алмасам да
барысын да,
Мин үтәдем
изге бурычымны
Ватаным һәм халкым каршында!..

Өнсез калды бөтен хөкем залы...
Үткәннәрнең авыр сагышын
хәтерләтеп кинәт,
Әйтерсең лә
яңгырап китте
Тельман тавышы:
– Юк!
Куркытмый мине бу гаепләү,
Мин кылмадым җирдә хыянәт.
Сезнең гаеп,
Гитлер палачлары,
Җир йөзендә сезнең җинаять
Үз җәзасын көтә!!

– Җитте! Тукта!!

Һәм күтәрә палач балтасын:
– Юк итәргә үзен!
Каберен!!
Сүзен!!!
Ватанына исеме кайтмасын!!!

## СОҢГЫ ҖЫР

– Үлем! – диде палач,
тик бу хөкем
Тетрәтмәде Муса күңелен.
Беләмени палач
шагыйрь хисен,
Туган илгә аның мәхәббәтен
Үтерергә мөмкин түгелен!..

Таш камера...
Монда кем дә белми
Үлем кайчан килеп керәсен.
Тез чүкмәде шагыйрь,
җырлар язды:
Дәвам итте шагыйрь
көрәшен.
– Үзем үлгәч,
исемемне палач
Пычратмакчы Илем каршында.
Әй, җырларым,
тизрәк кайтыгыз да
Сөйләгез сез Аңа
барысын да.
Язын кайткан сайрар кошлар белән
Хәбәр көткән чакта улыңнан,
Язгы тургай булып, сагышларым –
Җырым кайтыр
соңгы юлымнан.
Җырым кайтыр
мәхәббәте булып,
Анты булып
тугры йөрәкнең.
Мин көрәштем
соңгы сулышкача,
Син бит үзең шуңа өйрәттең.
Газиз илем минем!!!

Шашынса да катыйль,
жанны кимереп,
Җелекләрне суырып алса да,
Тәмуг ясап
якты җир йөзендә,
Утлы упкыннарга атса да,
Җиңелмәдем,
нәфрәт утыннан мин
Ялкын алдым
соңгы җырыма,
Факел итеп илгә тугрылыкны
Күтәрдем мин көрәш кырында.

«Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш языма.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла».

Хөр йөрәгем,
кер кунмаган антым
Табар Илем шушы җырымнан,
Алар минем
кайнар каным белән
Төрмә ташларына уелган...

* * *

*Менә, улым,*
*шагыйрь Туган илен*
*Шулай сөйде,*
*шулай саклады.*
*Ватанына биргән изге антын*
*Йөрәк каны белән аклады.*

*Җиңү килгәч илгә*
*язлар белән,*
*Исеме кайтты аның*
*җыр булып,*
*Ул яулаган бәхет*
*сезнең йөздә*
*Балкый бүген,*
*якты нур булып.*

*Васыять итеп тиңсез гүзәл гомерен,*

*Еллар аша сезгә дәшә ул:*

*Туган илгә гомерең багышласаң,*
*Мәңге калыр җирдә яшәвең...*

*звенела в народе*

Татарская литература богата яркими именами выдающихся творческих личностей. Но имя поэта-героя Мусы Джалиля занимает среди них особое место. Это личность не просто выдающаяся, а по-своему уникальная.

Указом Президиума Верховного Совета СССР от 2 февраля 1956 года за исключительную стойкость и мужество, проявленные в боях с немецко-фашистскими захватчиками в Великой Отечественной войне, Мусе Джалилю посмертно присвоено звание Героя Советского Союза. А ещё через год Комитет по Ленинским и Государственным премиям в области литературы и искусства при Совете Министров СССР присудил Мусе Джалилю – первому среди поэтов – Ленинскую премию за цикл стихотворений «Моабитская тетрадь».

До сегодняшнего дня Муса Джалиль остаётся единственным писателем нашей необъятной Родины, удостоенным одновременно этих двух высших правительственных наград. Других подобных нет не только в Татарстане, но и на всей территории бывшего Советского Союза.

В этом факте наглядно проявилось общенародное признание поэзии Мусы Джалиля как яркого образца героического искусства. Творческое наследие поэта-патриота стало ныне интернациональным достоянием.

В предисловии к одному из сборников Мусы Джалиля народный поэт Башкортостана Мустай Карим писал: «Мы благодарно думаем о татарской нации, сыном которой является Муса Джалиль. Именно такие, как полномочные послы, представляют свою Родину во всемирном духовном общении народов и племён. По ним судят люди мира о разуме и сердце народа, породившего их».

Подвиг Мусы Джалиля и сегодня, несколько десятилетий спустя, служит примером подлинного мужества, верности гражданским идеалам. На его примере молодое поколение учится патриотизму, приобщается к высоким ценностям.

Поэма Резеды Валеевой ярко, образно, красочно, доступным языком раскрывает суть подвига татарского поэта. Уверен, что те из читателей, кто сердцем приобщится к подвигу Мусы Джалиля, не совершат в своей жизни дурных поступков, вырастут верными сынами своей Родины.

Всё дальше уходят в прошлое события Великой Отечественной войны. Выросли уже новые поколения, знакомые с минувшей войной лишь по фильмам и книгам. Но подвиг народа живёт. И Муса Джалиль навечно с нами. Его имя носят улицы, колхозы, театры, клубы, пароходы. Его именем названы посёлок городского типа в нефтяном районе Татарстана и центральный проспект в Набережных Челнах, улица в молодом посёлке Беркакит на БАМе, одна из высочайших вершин в Антарктиде и малая планета (астероид), открытая в Крымской астрофизической обсерватории.

В Казани, на площади Первого Мая, неподалёку от Казанского Кремля возведён памятник Мусе Джалилю (автор – скульптор В.Е.Цигаль). Это памятник мужеству солдата и стойкости поэта. Но лучшим памятником поэту-герою и всем погибшим в минувшей войне стали стихи Мусы Джалиля. Крохотные тетрадки, спасённые из тюрьмы, стали томами книг, изданных на разных языках. Миллионными экземплярами они разлетались по планете, находя приют всюду, где есть честные люди, влюблённые в жизнь и мирный труд, верящие в будущее человечества.

Настоятельно советую юным читателям вчитаться в эту книгу. Уверен, что после этого им захочется взять в руки стихи самого Мусы Джалиля и узнать о нём как можно больше. Жизнь поэта, прозвучавшая песней, служит прекрасным примером для подражания.

*Рафаэль Мустафин,*

писатель, лауреат Государственной премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая и Республиканской премии имени Мусы Джалиля

*Песнь о Джалиле*

*Жизнь моя песней звучала в народе,*
*Смерть моя песней борьбы прозвучит…*
*Муса Джалиль*

*Я вам расскажу*
*Про поэта-бойца.*
*Он с песней по жизни*
*Прошёл до конца.*

*И жизнь его песней*
*Недаром зовёт*
*Навеки ему*
*Благодарный народ.*

*Он любит и помнит*
*Героя войны,*
*Татарского сына*
*Великой страны.*

## ДЕТСТВО

В тихой деревне
Мальчишка родился,
Ясной улыбке
У солнца учился.
Он прикасался
Ногами босыми
К нежности трав
Необъятной России.
Пил из ладошек
Он в полдень лучистый
Светлую воду
Ручьёв серебристых.
В сердце входило
Бескрайнее небо,

Щедрое поле
С колосьями хлеба…
Время учило,
И добрые книжки.
Петь у народа
Учился мальчишка.
В песни вливалось
Величье Отчизны,
Трудно идущей
К радостной жизни.
Песни звенели
Свободой и светом…
Вырос мальчишка
Бойцом и поэтом.

## ВОЙНА

Пока не проснулись
Поля и леса,
На сонные травы
Ложилась роса.
И начало небо
Уже розоветь…
Но птицы в тот день
Не успели запеть.
Над мирной землёй
Взорвалась тишина…
В страну на рассвете
Вломилась война…
…Фашизм
        ненавидит
              свободную жизнь,
Её уничтожить
              хочет
                    фашизм.
Он всех разделил
На рабов и
          господ…
У нас же –
          свободный,
                 единый народ.
И будет законом
               всегда для него:
«Счастье Отчизны –
               превыше всего!»

И если идти
за неё нам на бой,
Становятся рядом
солдатами в строй
Рабочий,
колхозник,
учитель,
поэт.
И в мире сплочённее
армии нет!

ПОЭТ НА ФРОНТЕ

Около Волхова –
огненный ад,
Небо смешалось с землёй.
Взрыв за взрывом
гремят подряд,
Круглые сутки –
бой.
Гремящий ад
нельзя обойти,
Сквозь ливень
огня и свинца
Упорно рвутся
наши бойцы
Из вражеского кольца.
Потерям уже
потерян счёт.
Но снова команда:
– Вперёд!
Идут на прорыв
за взводом взвод,
И с ними – поэт идёт.
Ходить в атаку
ему не впервой,
Людей за собой вести.
Он – коммунист.
И долг его –
Быть всегда
впереди!
Быть примером
во всём
и всегда!

Покуда живой...
...Но вдруг –
Ударил взрыв...
И темнота...
И тишина вокруг...

...Словно сквозь сон
Слышит Муса,
Сквозь тяжелейший сон,
Чьи-то лающие голоса –
сразу со всех сторон.
С трудом глаза
открывает Муса,
Услышав шаги врага...
Сама к виску
пистолет поднесла
Слабеющая рука.
Если другого выхода нет,
Есть этот –
наверняка...
Но что это?..
Отказал пистолет...
Бессильно упала рука…

## В КОНЦЛАГЕРЕ

Лагеря,
лагеря,
лагеря...
Лагеря –
Это голод и страх.
Не должно быть людей
в лагерях –
Существуют рабы
в лагерях.
О высоком и добром –
забудь,
Покорись
неизбежной судьбе.
Зверем,
мразью униженной будь,
Задуши
человека в себе.

Жизнь продлится хотя бы на день,
Отупей,
опустись,
озверей...
В лагерях
не должно быть людей.
Это – подлый закон лагерей.
Но не дрогнет
поэт-коммунист.
Он всегда
и во всём –
Человек!
Сердцем он перед Родиной чист.
Нет,
Такого не сломить и вовек!
Он товарищей ищет себе,
Говорит он
попавшим в беду
О борьбе,
о борьбе,
о борьбе.
Даже в лагерном сером аду.

## ВЫБОР ДЖАЛИЛЯ

Трещит хребет у фашистского зверя,
Дело к расплате идёт неуклонно...
Пленных сгоняют,
оружье доверив,
В «национальные легионы».
Пускай отчаявшиеся стреляют
На фронте
в своих же собственных братьев,
У рейха
надёжных солдат не хватает,
Дело идёт к расплате.
Каждому
в бой уходящему нужно
Сказать –
за что он сражаться уходит.
И здесь становится слово

оружием,
Слово на битвы армии водит.
Но слово нужно
и трусам презренным,
Словом склоняют к измене,
Оно заставляет
встать на колени –
Словом склоняют к измене,
Становится слово
оружием страшным
Против подлецов отпетых.
Вот почему рейхсминистр
важной
Считает встречу с поэтом.

Розенберг
на лесть не скупится,
Дарует свободу и деньги.
За это
Должен Муса
заплатить сторицей
Могучим словом поэта.
Газете предателей
имя Джалиля
Необходимо –
чтобы верили ей.
В народе не просто Джалиля любили,
Певцом новой жизни
он был для людей.
Ложь для поэта –
страшнее смерти,
Честнее –
мёртвым лежать в могиле.
Перед народом
Муса в ответе...
Кажется,
выбора нет у Джалиля.
Но жить для поэта –
значит бороться,
В любых условиях,
без исключения.
Самим врагом
возможность даётся

Слово использовать
по назначению.
Выбор Джалилю
становится ясен,
Хотя и опасен он:
Муса в легионе
работать согласен.
Чтоб изнутри взорвать легион.

## БОРЬБА

Главный из жёстких законов борьбы
Твёрдо Мусой усвоен:
Поодиночке –
все мы слабы,
В поле один –
не воин.
Джалиль расширяет
подпольщиков круг
Настойчиво и осторожно.
С ним рядом –
Алиш, испытанный друг,
С ним вместе – Саттар надёжный.
Соратников, братьев
находит везде,
Хотя и опасна работа…
Набатом звучит
для верных людей
Священное слово – Свобода.
Каждому сила пули ясна,
Но сила своя –
у листовки.
И если правдива она,
честна,
Листовка – сильней винтовки.
Оружием этим
подпольный фронт
Пользуется умело…
Вера живёт,
что настанет черёд
И более крупного дела.
Сердце живёт
надеждой одной,
Светом её согрето, –

Что доведётся
          бойцу домой
Вернуться живым, с победой.
А не удастся
         прийти назад –
Родина не осудит.
И никогда
        верных солдат,
Павших в бою,
           не забудет!

## ПРОЩАНИЕ С ЛЕГИОНЕРАМИ

Вот, наконец,
Этот день настал –
Торжественный для врагов.
Батальон легиона «Идель-Урал»
К отправке на фронт готов.
Звонко прощальные речи звучат:
– Летите на бой,
            орлы!.. –
Легионеры в строю молчат.
Взгляды у них
           тяжелы.
Ненависть в сердце
              нужно таить,
Выдать себя
         нельзя.
«Выдержав всё,
            врага победить», –
Недаром клялись друзья.
Ненависть нужно вложить в удар –
Так молнией бьёт гроза…
В строгие лица
           башкир и татар
Вглядывается Муса.
С любовью,
        с надеждой,
              в последний раз...
Сердцем – он с ними весь...
Для них –

дорога домой началась.
Ему –
оставаться здесь.
– Летите, летите, орлы мои,
К Родине милой моей.
Знаю, пробьётесь через бои,
Верю, прорвётесь к ней.
Светит её негасимый свет
Нам среди моря тьмы.
Ей передайте от нас привет,
Позже вернёмся и мы.
Как вдалеке мы тоскуем по ней, –
Нету тоски сильней!
Вы отнесите родной стороне
Песни любви моей…

## РАДОСТЬ

Муса улыбается,
хотя и украдкой, –
Пришло сообщение из Белоруссии:
Бойцы легиона
вступили в схватку,
Не подвели,
не струсили.
Отборные части легионеров,
В которых работал он
неустанно,
Восстали
и, перебив офицеров,
В леса ушли,
к партизанам!
Выходит,
не зря он с друзьями рискует
В невидимой битве подполья...
Но как по оружию руки тоскуют!
С ним бы теперь
на волю!
Исхода борьбы
не знают заранее,
Но к схватке готовятся главной,
Верят джалиловцы:
грянет восстание
Неудержимой лавой!

## ИЗМЕНА

Даже румяное яблоко
Бывает порой с червоточиной,
И на ухоженном поле
Растёт иногда сорняк.
И временами встречаются
Люди –
  как будто прочные, –
Сразу нутро предателя
Не разглядишь никак.
Могут слова красивые
Они повторять без устали,
Но перед грубой силою
Вмиг
  рассыпаются в прах...
Нет ничего дороже им
Жизни своей единственной,
Совестью,
  мыслями,
    чувствами
В них управляет
    страх...

…Как вы его не узнали,
Джалиловцы, чистые люди?
Как он сумел затесаться
В стойких борцов отряд?..
С восстанием
   вы опоздали.
Не будет его.
   Никак!.. –
Предана организация.
Дальше –
  кровавый ад.

## ИСПЫТАНИЕ МУКОЙ

Свобода,
  ты казалась близкой,
Манила и вела на бой.
Но в сердце угасает искрой
Надежда встретиться с тобой…
Свобода –
   небо голубое –

Была и песней и мечтой.
Страшнее пыток и побоев
Расстаться с этой высотой.
И нет страданиям предела,
И тает искорка, дрожа...
Болит истерзанное тело.
Ещё сильней болит
душа...
...Джалилю изменяют силы,
Он от страданий изнемог.
Порою кажется могилой
Проклятый каменный мешок.
Но нет,
и с нею несравним он,
В могиле –
всё-таки покой,
А здесь –
от боли нестерпимой
Не можешь шевельнуть рукой!
И мысль терзает непрестанно –
И день и ночь,
и день и ночь:
«Как там друзья,
что с ними стало?
Нельзя ли им –
хоть чем –
помочь?
Приободрить
и поддержать словами,
Им стойкость передать свою:
– Друзья,
мы погибаем с вами,
Пускай в неравном, но –
в бою!
Как настоящие джигиты,
Держитесь
из последних сил.
Не будут Родиной забыты
Те, кто ей верность сохранил!»
…Нет,
не сломили пытки волю.
Но с волей
тело не в ладу...
Муса страдает,

и от боли
Он забывается в бреду.
И видит он родные лица
Друзей, соратников своих.
Но к ним
словами не пробиться,
И крик
не долетит до них.
Они безмолвны и суровы.
Их судьбы тоже решены.
На них рубахи в пятнах крови,
Их взгляды –
горечи полны.
И снова пытки и угрозы,
Не знаешь:
снится или нет.
Те дни –
из боли и допросов –
Похожи на безумный бред.
И муки кажутся веками,
Веками –
из одних ночей.
Заговорил бы даже камень
В руках умелых палачей...
– Кто связан был с твоею шайкой?
Кто был с тобою заодно?
И как тебе
себя не жалко,
Сломаем,
скажешь всё равно!

Но не сломали,
не согнули,
Душой всё так же твёрд поэт.
В бреду,
во сне ли,
наяву ли –
Одно твердили губы:
– Нет!

## СУД

Как будто другая планета,

Где зло называют
добром...
Преступники
судят поэта.
Батыру
грозят топором –
За верность сыновнему долгу,
За то, что не стал подлецом...
Муса
ненавистным подонкам
С презрением смотрит в лицо!
Они в приговорах жестоки,
Но сами не могут не знать,
Что плохи дела на Востоке,
Возмездия –
не миновать!
Они –
мертвецы, а не люди,
Они в человечестве –
гниль...
И чувствуют,
чувствуют судьи,
Что судит сегодня –
Джалиль!
И, слушая слово поэта,
трусливые души дрожат:
Напомнил Димитрова
этот
Насквозь прожигающий взгляд.
Сейчас бы,
сию же минуту,
Отправить Мусу под топор!
Им страшно, фашистам,
как будто
Читают себе приговор.

## ПОСЛЕДНИЙ БОЙ

Знает сегодня
весь мир восхищённый,
Память о подвиге свято храня:
Узник,
к смерти приговорённый,

Муки прошедший,
непокорённый,
Пишет стихи до последнего дня!
Зря ожидали
враги от поэта
Слов о пощаде
и слёзной мольбы.
В схватке –
за ним остаётся победа,
Песни полны
и отваги и света,
Песни его –
продолженье борьбы.
Бой против нечисти,
гнусной,
жестокой,
Песня ведёт,
окрыляя сердца.
Мужеству учат
чеканные строки,
Вере,
что мы побеждаем в итоге,
Если Отчизне верны до конца.

Сердце товарища
словом согрето,
Слово
врага беспощадно разит,
В слове –
звенящее сердце поэта,
Мужество песни,
в застенках пропетой,
Крепче камней твоих,
Моабит!
Были минуты
глубокой печали,
Сердце порою
сжимала тоска.
Снились Джалилю родные ночами...
В песне
щемящая грусть прозвучала:
«Родина,
как ты сейчас далека!»

Путь до неё
оказался неблизким...
Пусть до победы
Муса не дожил,
Словом поэта,
пером журналиста –
Что бы ни делал –
он героически
И беззаветно народу служил.

Шёл он на Родину
долгие годы –
Через застенки,
через бои.
Пусть он погиб,
но вернулся к народу
Песней бесстрашия,
песней свободы,
Песней великой и нежной любви.

*** * ***

*Закончен рассказ*
*Про поэта-бойца,*
*Но жизни поэта*
*Не будет конца.*

*Он в памяти нашей*
*Как песня живёт.*
*И песня его*
*Никогда не умрёт!*

*Мы памяти светлой*
*Навеки верны –*
*Свободные люди*
*Великой страны.*

Литературно-художественное издание

Для детей среднего и старшего школьного возраста

**Валеева** Резеда Тавгалюновна

**ПЕСНЬ О ДЖАЛИЛЕ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском и русском языках

Әдәби-нәфис басма

Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен

**Вәлиева** Резеда Тәфкалүн кызы

**МУСА ҖӘЛИЛ – ХАЛКЫМ УЛЫ**

Мөхәррирләре *Л.Ә.Гыйззәтуллина, Э.Р.Миңнуллина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *С.Н.Галимуллина, Э.Р.Миңнуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.05.2011.
Форматы 60x100 $^{1}/_{16}$. Шартлы басма табагы 4,4.
Тиражы 2000 д. Заказ Р-636.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.